Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай
урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 26 нчы августыннан № 16

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге»нең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 28 статьясы нигезендә № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, « Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы , Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәләр Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының "Камай авыл җирлеге"муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын карап тикшерү буенча ачык тыңлауларны 2021 елның 27 нче сентябрендә 15 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Камай авыл җирлеге, Камай авылы, Дифгать Сирая урамы, 29а йорты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең КФҮ.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын карап тикшерү буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә "Камай авыл җирлеге"муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты белән танышу чорында әлеге проектның демонстратив

материаллары экспозициясен оештырырга, кызыксынган затларның искәрмәләре һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Камай авыл җирлеге, Камай авылы, ул. Дифгать Сирая, 29а йорты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең күпфункцияле үзәге;

5. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ рәсми сайтында Камай авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

Камай авыл җирлеге Советы рәисе И.И.Әһлиева

Кушымта
Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Камай авыл
җирлеге Советының 2021 елның
26 августыннан 16 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге"муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын карап тикшерү буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча
комиссия составы

1. Рәисе: Әһлиева Инзилә Ильяс кызы -Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Рәис урынбасары: Кәлимуллин Рәмис Рафис улы - Камай авыл җирлеге Советы депутаты;
3. Секретарь: Зиннәтуллина Гүзәлия Мөнир кызы-Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
4. Комиссия әгъзасы: Аннаморадова Римма Борисовна-Камай авыл җирлеге Советы депутаты;
5. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы» инвестицион һәм инфраструктура үсеше идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.